**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сәпәй авылы № 61 «11» сентябрь 2017 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

«Сәпәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә Сез ризамы?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) Мәктәп урамындагы зиратны киртәләү;

3) юлларны кышкы тәртиптә тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Сәпәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:

- ТР, Азнакай районы ,Сәпәй авылы, Мәктәп урамы, 53В йорты;

- Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мачаклы -Баш авылы, Урман ур., 10 йорт ,

- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru. ,

Рәис Ф.Г.Галиева